Республика Татарстан

**ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т.Уруссу ул.Пушкина, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

Татарстан Республикасы

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

423950, Урыссу ш.т.б. Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**“27” 04 2020 г.** №31

Ютазы муниципаль районы Башлыгының
2019 елның 12 декабрендәге “Административ
хокук бозулар турында беркетмәләр
төзергә вәкаләтле вазифаи затлар исемлеге турында”
№84 карарына үзгәрешләр кертү турында

Җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларының вәкаләтләрен киңәйтү, шулай ук аларны «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 2020 елның 24 апрелендәге 17-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы таләпләренә туры китерү максатларында, карар бирәм:
1. Кушымтаны түбәндәге эчтәлекле бүлек белән тулыландырырга:

| ТР Административ хокук бозулар турында Кодексының статьялары | Статьяның эчтәлеге | Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары |
|---|---|---|
| ТР Административ хокук бозулар турында Кодексының 2.17 ст. | Яңа короновирус инфекциясе (COVID-19) таралуын булдырмый калуга һәм бетерүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы | Ютазы муниципаль районы Советының җирлекләр белән эшләү буенча бүлеге начальнигы |

| | | |
|---|---|---|
| | норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү | |

2. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының **http://jutaza.tatarstan.ru** рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Ютазы муниципаль районы
башлыгы урынбасары З.М. Әгълиева

З.М.Латыйпова
2-67-71